Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 сентябрендәге 14 номерлы “Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында” карары

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге N 339-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 17 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 10 августындагы 6 номерлы Югары Ындырчы авыл җирлеге башкарма комитетының карары белән расланган нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү.».

2.Әлеге карар 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга. 4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Җирлек башлыгы Ф.М.Гафиятуллин